**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об объявлении 2018 года в Республике Татарстан Годом Льва Толстого

В целях привлечения общественного внимания к вопросам развития культуры и языкознания, признавая значительное влияние творческого наследия великого русского писателя Льва Николаевича Толстого на отечественную и мировую литературу, учитывая тесную связь семьи Толстых с Казанью, а также 190-летие со дня рождения Льва Николаевича Толстого, **постановляю**:

1. Объявить 2018 год в Республике Татарстан Годом Льва Толстого.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан:
в месячный срок образовать организационный комитет по проведению в Республике Татарстан Года Льва Толстого и утвердить его состав;
в трехмесячный срок разработать и утвердить план основных мероприятий по проведению в Республике Татарстан Года Льва Толстого.

3. Предложить главам муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан организовать работу по проведению на территориях муниципальных образований мероприятий в рамках Года Льва Толстого.

4. Предложить государственным органам Республики Татарстан, общественным объединениям и организациям принять активное участие в подготовке и проведении в Республике Татарстан Года Льва Толстого.

5. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа», республиканским и местным средствам массовой информации обеспечить широкое освещение проведения в Республике Татарстан Года Льва Толстого.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань,Кремль
21 сентября 2017 года
№ УП-832

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## 2018 елны Татарстан Республикасында Лев Толстой елы дип игълан итү турында

Җәмәгатьчелекнең игътибарын мәдәният һәм тел белеме үсеше мәсьәләләренә җәлеп итү максатларында, бөек рус язучысы Лев Николаевич Толстой иҗади мирасының илебез һәм дөнья әдәбияты үсешенә зур йогынтысын танып, Толстой гаиләсенең Казан белән тыгыз элемтәләрен, шулай ук Лев Николаевич Толстойның тууына 190 ел тулуны исәпкә алып **карар бирәм**:

1. 2018 елны Татарстан Республикасында Лев Толстой елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай эчендә Татарстан Республикасында Лев Толстой елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай эчендә Татарстан Республикасында Лев Толстой елын уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Лев Толстой елын уздыру эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Лев Толстой елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Лев Толстой елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 21 сентябрь
№ ПУ-832